ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина**

# ТЕЛНЕҢ КҮРКЕ – СҮЗ

## МЕТОДИК ӘСБАП

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен

Казан
2021

**УДК 811.512.145**
**ББК 81.2-9**
**Ш 92**

*Методик әсбап*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында*
*эшләнде*

*«Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024 еллар)»*
*Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында*
*әзерләнде һәм нәшер ителә*

**Шәкүрова М.М.**
**Ш 92** **Телнең күрке – сүз.** Методик әсбап: Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина. – Казан, 2021. – 60 б.
ISBN 978-5-93091-396-5

Методик әсбапта мәктәпкә әзерлек һәм зурлар төркемнәре өчен Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандарты таләпләре нигезендә төзелгән материал тәкъдим ителә. Әсбап балаларга сәнгати-эстетик яктан тәрбия бирү мәсьәләләренә багышлана, балаларны татар халкының сәнгате, әдәбияты, мәдәнияте һәм тарихы белән таныштыруны максат итеп куя.

Әсбап 6–7 яшьлек балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә, татар теле укытучыларына ярдәмлек буларак әзерләнде.

УДК 811.512.145
ББК 81.2-9

**ISBN 978-5-93091-396-5**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2021
© Шәкүрова М.М., 2021
© Гыйниятуллина Л.М., 2021

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Әлеге методик ярдәмлек балалар бакчасында 6–7 яшьлек балалар белән эшләүче татар теле тәрбиячеләре, татар теле укытучылары өчен әзерләнде. Ярдәмлек мәктәпкәчә яшьтәге балаларга сәнгати-эстетик яктан тәрбия бирү мәсьәләләрен үз эченә ала, балаларны татар халкының сәнгате, әдәбияты, мәдәнияте һәм тарихы белән таныштыруны максат итеп куя. Ул балаларга сәнгатьнең төрле төрләре һәм жанрлары (сүз, музыка, рәсем), шул исәптән халык иҗаты турында мәгълүмат бирү; музыка, сәнгать, әдәбиятны, фольклорны кабул итү сәләтен үстерү; сәнгати-эстетик эшчәнлекнең төрле төрләренә җәлеп итү, иҗадилыкларын арттыру, инициативалылык һәм мөстәкыйльлекләрен үстерү кебек бурычларны тормышка ашырырга ярдәм итәчәк.

Дөньяга карата эстетик мөнәсәбәт тәрбияләү – чынбарлыкны төрле сизү органнары аша кабул итү дигән сүз. Тәрбияче балаларда тотып карап кабул итү сәләтен генә үстереп калмый, хистойгыларын баетуга, табигать һәм хайваннар дөньясы матурлыгына эмоциональ ярдәмчеллекне үстерүгә, сәнгать, әдәбият һәм фольклор персонажларының кичерешләрен уртаклашырга да өйрәтә. Балаларны кечкенәдән үк классик әдәбият, рәсем, музыка, театр сәнгате әсәрләре, халык иҗаты әсәрләре белән таныштыру, сәнгать альбомнарындагы иллюстрацияләрне күрсәтү, табигатькә, музейларга экскурсияләр оештыру, тиешле эчтәлектәге фильмнар күрсәтү, башка сәнгати-эстетик мәгълүмат чыганакларына мөрәҗәгать итү зарур.

Әлеге методик ярдәмлектә темалар 4 лексик блокка бүлеп бирелде: «Мин», «Әйләнә-тирә дөнья», «Туган илем», «Татар дөньясы». Блоклар эчендәге лексик темалар «Авыз күрке – тел» методик ярдәмлегендәге темалар белән бәйләп алып барыла. Тәрбиячеләргә шушы ике ярдәмлек белән параллель рәвештә эшләргә тәкъдим ителә. Һәр ярдәмлек үз эченә егерме өчәр шөгыльне берләштерә.

# МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРНЫ СӘНГАТИ-ЭСТЕТИК ЯКТАН ҮСТЕРҮ

«Сәнгати-эстетик үсеш» белем бирү өлкәсенең төп максатлары һәм бурычлары:

1. Сәнгатькә тарту. Әдәби һәм музыкаль әсәрләрне, әйләнә-тирә дөньяның, сәнгать әсәренең матурлыгын эмоциональ бәяләүне үстерү.

Илебез һәм чит илләр сәнгатенең иң яхшы үрнәкләре белән таныштыру ярдәмендә балаларны халык сәнгатенә һәм профессиональ сәнгатькә тарту; сәнгать әсәрләренең эчтәлеген аңлый белү сәләте тәрбияләү.

2. Сурәтләү эшчәнлеге. Сурәтләү эшчәнлегенең төрле төрләренә карата кызыксынуны үстерү; рәсем ясау, әвәләү, аппликация, гамәли иҗат күнекмәләрен камилләштерү.

Сынлы сәнгать әсәрләре белән танышканда эмоциональ тоемлый белү сыйфатын тәрбияләү.

Коллектив эшләр башкарганда яшьтәшләре белән бергәләп эшләү теләге һәм эшли белү сыйфаты тәрбияләү.

3. Конструкцияләү-модельләү эшчәнлеге. Конструкцияләүгә тарту; конструкцияләү эшчәнлегенә карата кызыксынуны үстерү, конструкторларның төрле төрләре белән таныштыру.

Коллектив эшләү, үз эшләнмәләреңне гомуми ният кысаларында берләштерү, эшнең кайсы өлешен кем башкарачагы турында сүз куеша белү сыйфаты тәрбияләү.

4. Музыкаль эшчәнлек. Музыкаль сәнгатькә тарту; музыка сәнгатен кыйммәт-мәгънә ягыннан кабул итү һәм аңлауны үстерү; музыкаль культура нигезләрен формалаштыру, элементар музыкаль төшенчәләр, жанрлар белән таныштыру; музыка әсәрләре белән танышканда эмоциональ тоемлый белү сыйфатын тәрбияләү.

Музыкаль эшчәнлек өчен зарур сыйфатлар: шигъри һәм музыкаль тоем, ритм хисен, музыкаль хәтерне үстерү; җыр зәвыгы, музыкаль зәвык формалаштыру.

Музыкаль-сәнгати эшчәнлеккә карата кызыксыну тәрбияләү, эшчәнлекнең бу төрендәге күнекмәләрне камилләштерү.

5. Уен эшчәнлеген үстерү (театральләштерелгән уеннар). Балаларда театр сәнгатенә кызыксыну формалаштыру. Театр культурасы күнекмәләре тәрбияләү. Балаларның иҗади потенциалын ачу, артистлык сәләтләрен үстерү. Иҗади мөстәкыйльлекләрен, эстетик зәвыкларын үстерү.

## МИН

БЕРЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

### Җырлар: Иң кадерле кешеләр

**1. Тәрбияче балаларга шигырьне укый.** Авторы белән таныштыра.

***Җирдә миңа ни кирәк?***

Җирдә миңа ни кирәк?
Әти дә әни кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Без яшәгән өй кирәк!
Әти дә әни кирәк!
Без яшәгән өй кирәк!

*Шәүкәт Галиев*

**2. Тәрбияче «Безнең өчен иң кадерле кешеләр» темасына балалар белән әңгәмә уздыра.**

**3. Бу шөгыльдә дүрт җыр тәкъдим ителә.** Тәрбияче берсен сайлап алып эшли.

**Беренче җыр әбиләргә багышлана.**

***Әбием-әбекәем***

*Рөстәм Бакиров сүзләре*
*Рөстәм Сәрвәров музыкасы*

Балам, дия-дия безне
Кадерләп үстерәсең,
Әй, матур син, әбекәем,
Күзләр тия күрмәсен!

Кушымта:

Әй, әбием, әбекәем,
Кояш кебек күңелең,
Сәламәтлек бирсен Ходай,
Озын булсын гомерең.

Өебезнең нуры бит син,
Рәхмәт яусын үзеңә.
Бәхетле без, әбекәем,
Син булган өчен генә.

Бу җырны QR-код яки https://youtu.be/aIfCggVQVow сылтамасы аша узып, керep тыңларга була.

**Тәрбияче балаларга шигырьне укый.** Авторы белән таныштыра.

***Булышчы***

Әниемә эш күп өйдә –
Мин шуңа да булышам.
Менә әле дә мин аңа
Чынаяклар юышам.

Булышам шул, юышам шул,
Мин бит инде булышчы.
Уф, арыдым! Һаман бетми!
Әнием, кил, булышчы!

*Роберт Миңнуллин*

**Икенче җыр әниләргә багышлана.**

***Әнкәй янда булганда***

*Гөл Мирһади сүзләре*
*Эльвира Хәмәтнурова көе*

Яратам иртәләрне
Уятса әнкәй сөеп,
Чакырса чәй эчәргә
Тәмле коймаклар оеп.

Кушымта:

Нинди рәхәт,
Нинди рәхәт
Әнкәй янда булганда,
Кочагына алып сөеп,
Назлап кына торганда.

Әнкәй карап торганда
Хәрефләр язам тезеп,

Мисалларны да эшлим
Азакка тиклем, түзеп.

Кушымта.

Әнкәй теләп калганда
Бишлеләр дә элгә,
Арымыйм да, талмыйм да,
Тарымыйм да бәлагә.

Кушымта.

Кичен әкият сөйләп
Куенында йоклата.
Еласам яшем сөртеп,
Үскәнем дип юата.

Бу җырны QR-код яки https://www.youtube.com/watch?v=XXw9YvZLLzo сылтамасы аша узып тыңларга була.

**Тәрбияче балаларга шигырьне укый.** Авторы белән таныштыра.

***Бер шигырь***

Без эти белән икәү
Охшаганбыз төс белән.
Борныбыз да кәкере,
Авызыбыз да кечкенә.

Әти мине ярата,
Бик кадерләп үстерә.
Мин йөткерсәм, йөткерә,
Мин төчкерсәм, төчкерә.

Әти миңа ошаган,
Мин этигә ошаган.
Әти миңа ышана,
Мин этигә ышанам.

Алма агачыннан
Ерак төшми диләр бит.
Алтын була кечкенә,
Артык үсми, – диләр бит.

*Муса Җәлил*

**Өченче җыр әтиләргә багышлана.**

***Әтиемә***

*Рәмзия Вәлиуллина сүзләре*
*Эльвира Хәмәтнурова музыкасы*

Әтиемнең йолдызы мин –
Ул миңа шулай дәшә.
Тәмле кәнфит, чикләвек,
Уенчык алып кайта.

Кушымта:

Бер матур җыр бүләк итәм –
Әтием җыр ярата.
Лә-лә-лә...

Кулымнан тотып әтием
Иртән бакчага илтә.
Үзенең эше беткәч,
Алырга килеп җитә.

Кушымта.

Кичен әкият укыйбыз
Әтием белән бергә.
Бик яратам әтиемне,
Алдыннан төшмим бер дә.

Бу җырны QR-код яки https://page.ligaudio.ru/mp3/камилә%20насырова (Камилә Насырова) сылтамасы аша узып тыңларга була.

**Тәрбияче балаларга шигырьне укый.** Авторы белән таныштыра.

Минем бабай белән әби
Кояшны уздыралар:
Кояштан соң яталар да
Таң атканчы торалар.

*Мөҗәһит Әхмәтҗанов*

**Дүртенче җыр бабайлар турында.**

***Иң шәп бабай***

*Рөстәм Бакиров сүзләре*
*Рөстәм Сәрвәров музыкасы*

Сөенеп туймас балачак,
Иң бәхетле балачак.
Бабай белән үткән кичләр
Мәңге истә калачак.

Кушымта:

Яратабыз сине, бабай.
Син бит безнең бер генә.
Нурлы йөзле, шат күңелле,
Иң шәп бабай – син генә.

Синең эзләр сакланадыр
Бормалы сукмакларда.
Хәй бабакай, диябез без
Бик сагынган чакларда.

Бу җырны QR-код яки https://power.gybka.com/song/31963807/Ajsylu_-_in_shep_babaj/ сылтамасы аша узып тыңларга була.

ИКЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Җырлар: Дүрт аяклы дусларыбыз

**1. Тәрбияче балаларга шигырьне укый.**

### *Өрә белүче шкаф*

Барыбыз беткәч ятып,
Шкафыбыз бервакыт
Әй өрергә тотынды –
Алды бөтен котымны!

Өрә-өрә, туктамый –
Беребез дә йокламый.
Ачкан идем ишеген,
Килеп чыкты көчегем!

*Роберт Миңнуллин*

**2. Тәрбияче «Дүрт аяклы дусларыбыз» темасына балалар белән әңгәмә уздыра.**

**3. Бу шөгыльдә ике җыр тәкъдим ителә.** Тәрбияче берсен сайлап алып эшли.

**Беренче җыр эт турында.**

### *Маэмай*

*Муса Җәлил сүзләре*
*Фәрит Яруллин музыкасы*

Бар минем маэмаем,
Кара борын Акбаем.
Күп йөгерә, күп өрә,
Күп ишетә, күп күрә.

Хәзер аңа мин төрле
Һөнәрләрне өйрәтәм.
Чаптырам да сикертәм,
Көн дә шулай йөдәтәм.

Бу җырны QR-код яки https://power.gybka.com/song/47457166/Idris_Gaziev_-_Maemaj_F.YArullin_muzykasy_M._lil_s_zl_re/ сылтамасы аша узып тыңларга була.

**Тәрбияче балаларга шигырьне укый.** Авторы белән таныштыра.

***Сөенеч***

Сөенеч!
Сөенеч! –
Песиебез хәзер өч:
Зурысы – әни песи,
Икесе – бәби песи.
Бәбинең берсе ап-ак,
Ә берсе – кара колак.
Агына исем – Аппак,
Кара колакка – Шапшак.

*Ренат Харис*

**Икенче җыр песи баласы турында.**

***Шаян песи***

*Лилия Таймасова сүзләре*
*И. Гыйләҗев музыкасы*

Безнең песи иллә шаян
Уйнарга бик ярата.
Күрмәмешкә салышканда
Килеп аяктан тарта.

Песи, песи, песи,
Нечкәбил.
Минем нәни
Шаян песием.

Бар белгәне уен гына.
Иртә ни дә,
Кичен ни.
Әти әйтә: «Җитте сиңа,
Эшең беткән, юньсез!, – ди.

Бу җырны QR-код яки https://power.gybka.com/song/156773064/Balalar_yrlyj_-_SHayan_pesi_L.Tajmasova_s_z._I.Gyjl_ev_muz./ сылтамасы аша узып тыңларга була.

ӨЧЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Уеннар

**1. Тәрбияче җырның сүзләрен бер тапкыр укый.** Хәрәкәтләр белән җырны бергәләп җырлыйлар. Балалар парлашып басалар.

***Эх, зилем, зиләле***

| | |
|---|---|
| Менә сиңа уң кулым, | *бер-берсенә уң кулларын бирәләр* |
| Менә сиңа сул кулым. | *бер-берсенә сул кулларын бирәләр* |
| Менә сиңа якын дустым, | *бер-бер артлы кулларын биреп* |
| Менә сиңа куш кулым. | *бер-берсе белән чәбәкләшәләр* |
| Эх, зилем, зиләле, | *кулга-кул тотынышып,* |
| Сандугачым, кил әле. | *парлап әйләнәләр* |
| Кил әле, дустым, кил әле, | |
| Икәү әйләник әле. | |

Бу җырны QR-код яки https://stand.hitplayer.ru/?s=%D1%8D%D1%85%2C%20%D0%B7%D0%B8%D0%BB%D0%B5%D0% BC-%D0%B7%D0%B8%D0%BB%D3%99%D0%BB%D0%B5 сылтамасы аша узып тыңларга була.

**2. Тәрбияче балалар белән «Ак, димә, кара, димә...» уенын оештыра.** Уенның максаты: балаларның уйлау сәләтен үстерү, аларда игътибарлылык, тапкырлык сыйфатлары тәрбияләү.

Балалар тезелеп утыралар. Санамыш ярдәмендә сорау бирүче билгеләнә. Ул балаларга төрле сораулар бирә. Аңа җавап бирүче «ак», «кара», «әйе», «юк» димәскә тиеш. Башны түбән ияргә һәм көләргә дә ярамый. Сорау алучы, бер баланың каршына басып, әйтергә ярамаган сүзләрне әйттерү өчен, юри сораулар бирә:

– Синең күлмәгең нинди, акмы?
– Кызыл.
– Синең аягыңда туфлимы?
– Итекләр.
– Сөтнең төсе нинди? һ. б.

Әгәр бала, ялгышып, әйтергә ярамаган сүзләрнең берәрсен әйтсә, йә булмаса башын исә, яки көлеп җибәрсә, ул бала сорау алучы була. Уенның кагыйдәсен шигырь юллары белән әйтеп, уенны дәвам итә:

«Ак», димә, «кара», димә,
Башыңны түбән имә.
«Әйе», димә, «юк», димә,
Көлмә, елмайма.

ДҮРТЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

**Төрле кул эшләре турында мәгълүмат бирү**

**1. Тәрбияче матур күлмәк кигән курчакны күрсәтә һәм шигырьне бер тапкыр укый.**

***Минем әнием – тегүче***

Өстемдәге күлмәгемә
Күпләр карый сокланып.
«Кем текте?» – дип, кайберләре
Сорап куя, тукталып.

«Әнием, дим, әни минем –
Фабрикада тегүче».
Бер мин генә түгел әле
Ул теккәнне киюче.

*Әнәс Кари*

1) Без кия торган матур күлмәкләрне, чалбарларны кемнәр тегә?
2) Тегү өчен нәрсәләр кирәк? *(тәрбияче энә, җеп, тукыма, кайчы күрсәтә)*

**2. Бераз ял итеп алу максаты белән, тәрбияче «Бармак» уены уйнарга тәкъдим итә.**

Баш бармагым – биюче,
Имән бармак – итекче.
Урта бармак – укытучы,
Атсыз бармак – аучы.
Чәнти бармак кем була?
Читек чигүче була.

*Фәрсия Зиннурова*

**3. Тәрбияче, чигелгән читек рәсеме (яки читекнең үзен) күрсәтеп, әлеге татар милли аяк киеме турында сөйли.**

Тәрбияче, һәр балага җитәрлек итеп, төсле кәгазьдән читек рәсемнәре һәм бизәкләр әзерли. Әлеге бизәкләрне читеккә ябыштырып, балалар үзләренең читекләрен бизиләр.

**4. Тәрбияче балаларга йон оекбаш күрсәтә.** Бәйләү өчен җеп, биш энә кирәк була. Тәрбияче шигырьне укый.

***Оекбаш***

Кыш көне салкын булса да,
Һич туңмый минем аяк.
Җылыта аны дәү әни
Бәйләп биргән йон оек.

Сарык йоны җылы була.
Бар бит тагын шунысы –
Күчкән аңа дәү әнием
Кулларының җылысы.

*Рафис Корбан*

Тәрбияче ике энәгә күзләр җыеп, мастер-класс үткәрә. Һәр бала энәне тотып, 1–2 күз бәйләп карый.

**5. Тәрбияче балалар белән бергә «Башмакчы» уены уйный.**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Тәрбияче кулына бер башмак алып (уйнаучы балаларның аяк үлчәменнән башмак зуррак булырга тиеш), уртага баса. Җырлый:

Төрле һөнәр беләбез,
Матур итеп тегәбез;
Асыл төсле җепләр белән
Башмак башын чигәбез.

Балалар аңа каршы, түгәрәк буйлап йөреп, җыр җырлыйлар:

Әй башмакчы, башмакчы,
Үзең – оста такмакчы.
Син җырлама такмагың,
Бир кияргә башмагың.

Балалар җырлап бетергәч, тәрбияче башмакны 2 бала арасына куя һәм аларның иңнәренә кагыла. 2 бала икесе ике якка түгәрәк буйлап йөгереп китәләр. Кем беренче килеп җитә, шул башмакны кия. Ул «башмакчы» була. Уен яңадан башлана.

БИШЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Шагыйрьләр

**1. Тәрбияче Шәүкәт Галиевнең фотосурәтен күрсәтә, шагыйрь турында кыскача мәгълүмат бирә.**



Шәүкәт Галиев – татар язучысы, балалар шагыйре. Ул сезнең өчен бик күп шаян шигырьләр язган. Шәүкәт абыегыз Галиевнең шигырьләре сезне рәхәтләнеп көлдерә, яхшыны начардан аерып күрсәтә. Шагыйрь язган вакыйгалар онытылмый, укучыны үзенә тарта.

Шәүкәт Галиевне беләм
Безгә шигырьләр язган.
Шәвәли – аның герое.
Ул да кунакка килгән.

**2. Тәрбияче шигырьне укый.** Сабантуйда балалар көрәшенә багышланган рәсем күрсәтә.

***Сабан туе батыры***

Быел батыр кем дисәң,
Батыр калды Шәвәли.
Зур мәйданда берүзе
Басып калды Шәвәли!

Басып калды Шәвәли –
Екты ул барчасын да.
Батыр калды Шәвәли
Балалар бакчасында!

*Шәүкәт Галиев*

Шигырь тексты белән эшләү өчен сораулар:

1) Шигырьне кем язган?
2) Шигырьнең герое кем?
3) Шәвәли нинди?
4) Шәвәли Сабантуйда кайсы ярышта катнаша?
5) Сез бакчада Сабантуй бәйрәме үткәрәсезме?
6) Сабантуйда тагын нинди ярышлар оештырыла?

**3. Тәрбияче Роберт Миңнуллинның фотосын күрсәтә, шагыйрь турында кыскача мәгълүмат бирә.**



Роберт Миңнуллин – күренекле балалар шагыйре. Без сезнең белән Роберт абыегызның «Булышчы», «Өрә белүче шкаф» шигырьләрен укыдык. Шагыйрьнең «Әни, мин көчек күрдем!», «Энекәш кирәк миңа!», «Без айга оча яздык» һәм башка бик күп шигырьләре дә таныш сезгә. Роберт Миңнуллин язган күп кенә шигырьләргә композиторлар көй язган. Без сезнең белән ул җырларны да яратып җырлыйбыз. «Балачак бәйрәмнәре», «Тынычлык маршы», «Ак кыш», «Зәңгәр яз», «Яшел җәй», «Сары көз», «Чыршы әйләнәсендә» шундый җырлар.

Әйдәгез, бер җырны бергәләп тыңлыйбыз.

***Чыршы әйләнәсендә***

*Роберт Миңнуллин сүзләре*
*Рамил Курамшин музыкасы*

Каршылыйк, дуслар, бергәләп:
Яңа ел килә безгә!
Әнә күпме кунак килгән
Әйләнә-тирәбезгә.

Йолдызлар төшеп кушылган
Чыршыдагы утларга.
Кыш бабай белән Кар кызы
Килгән безне котларга.

Кыш бабай килгәч, булачак
Котлаулар да, бүләк тә!
Яңа елда чынга ашар
Безнең бөтен теләк тә!

Яңа елның бәхетле ел
Буласын без беләбез.
Шуңа күрә бергәләшеп
Яңа елга керәбез!

Рәхмәт сиңа да, иске ел!
Матур ел булдың бит син.
Синнән алган бәхет-шатлык
Гомер буена җитсен!

Бу җырны QR-код
яки https://stand.hitplayer.ru/?s=%D1%87%D1%8B%D1%80%D1%88%D1%8B%20%D3%99%D0%B9%D0%BB%D3%99%D0%BD%D3%99%D1%81%D0%B5%D0%BD%D0%B4%D3%99 сылтамасы аша узып тыңларга була.

Тәрбияче:

Роберт абый Миңнуллинны
Юктыр белмәгән бала.
Әнә аның герое да
Безгә килгән кунакка.

**4. Тәрбияче шигырьне укый.** Шигырьнең герое турында сөйләшү үткәрә.

***Хәйләкәр малай***

Берәр мутлык эшләдисәм,
Әни миңа: «Төлке!» – ди.
Өсти аннан: «Төлкедән дә
Хәйләкәр син түлке!» – ди.

Чыннан да, минем үземдә
Хәйләкәрлек җитәрлек,
Кирәк булса, ул төлкенең
Үзен кызык итәрлек!

Мине белсә, ул үзе дә
Сокланып туймас иде.
Минем алда берәүне дә
Алдарга кыймас иде.

Үзенең бөтен мутлыгын
Гел миңа өяр иде.
Улына: «Син Алмаз кебек
Хәйләкәр», – дияр иде.

Менә шулай хәйләләргә
Булдыралам мин генә...
Әй лә, ышана күрмәгез,
Юри хәйләлим генә.

*Роберт Миңнуллин*

Шигырь тексты белән эшләү өчен сораулар:

1) Төлке нинди?
2) Нинди кешеләргә төлке диләр?
3) Шигырьне язган шагыйрьнең исеме ничек?
4) Шигырьнең герое кем?
5) Алмаз нинди?

**5. Тәрбияче Муса Җәлилнең фотосын күрсәтә, шагыйрь турында кыскача мәгълүмат бирә.**

Муса Җәлил – сугышта үлеп калган герой-шагыйрь. Ул балалар өчен бик күп шигырьләр язган. Шагыйрь Муса Җәлил балалар белән еш аралаша.



Рәсемдә – шагыйрь үзе ясаган дәфтәрнең бер бите. Бу дәфтәр сигез биттән тора. Муса аны Әдип исемле дүрт яшьлек малайга бүләк итә. Җәлил шигырьләрне латин хәрефләре белән яза. Рәсемнәрне дә ул үзе ясый.



**6. Тәрбияче шигырьне укый.** Шигырьнең эчтәлеге буенча сөйләшү үткәрә.

***Әтәч***

Таң ата бугай,
Әтәч кычкыра:
– Кикрикүк,
Кикрикүк!
Йә сузып кына,
Йә бик еш кына,
– Кикрикүк,
Кикрикүк!
Без дә уяндык
Әтәч тавышына:
– Кикрикүк,
Кикрикүк!
Бакчага килдек,
Ашыга-ашыга:
– Кикрикүк,
Кикрикүк!

*Муса Җәлил*

Шигырь тексты белән эшләү өчен сораулар:

1) Муса Җәлил кем ул?
2) Әтәч кайчан кычкыра?
3) Сине йокыдан кем уята?

## АЛТЫНЧЫ ШӨГЫЛЬ

### Әкият укыйм

**1. Тәрбияче шигырьне укый. Балалар белән бергәләп сорауларга җаваплар бирәләр.**

***Әкиятләр яратам***

Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр – батырлар.
Бар бит анда ак аюлар,
Көчле Камыр Батырлар.

Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр – шаяннар.
Йөгерешә Җилаяклар,
Чакмый торган Чаяннар.

Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр – хәйләле.
Чөнки анда зирәк Былтыр,
Тагын елак Шүрәле...

Серле, кызык әкиятләрне
Тыңларга бик яратам.
Әкият сөйли дә этием,
Шундук йокларга ятам.

*Эльмира Шәрифуллина*

1) Син нинди әкиятләр беләсең?
2) Син нинди әкият геройларын беләсең?
3) Шүрәлене кем алдый?
4) Сиңа әкиятләрне кем укый.

**2. Тәрбияче Абдулла Алиш фотосын күрсәтә, язучы турында кыскача мәгълүмат бирә.**



Абдулла Алиш та сугышта батырларча үлгән татар язучысы. Ул балалар өчен бик күп әкиятләр язган. «Сертотмас үрдәк», «Нечкәбил», «Куян кызы», «Койрыклар», «Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык» әкиятләрен, алар буенча төшерелгән мультфильмнарны без дә беләбез.

Әйдәгез, «Сертотмас үрдәк» әкиятен бергәләп карыйк.

Бу әкиятне QR-код яки https://youtu.be/erMfEwNXl6o сылтамасы аша узып карарга була.

**Тәрбияче әкиятне укый.**

***Каз белән аккош***

Болын уртасында зур бер күл булган. Шул тыныч күлдә аккош белән каз яшәгән. Беркөнне бу ике күрше үзләренең балалары турында сөйләшкәннәр. Каз әйткән:

– Улым ашны аз ашый, суны гына күп эчә! – дигән.

Аккош әйткән:

– Минем балам бик яхшы ашый, зур үсә, – дигән.

Көннәрдән беркөнне каз белән аккошның балалары әниләренә килгәннәр дә:

– Әни, велосипед ал әле! – дигәннәр.

Әниләре уллары белән велосипед кибетенә киткәннәр.

Сатучылар аккошның улына велосипед алып килгән.

Аккош бәбкәсе велосипедка менеп атланган да йөгереп дә киткән. Каз бәбкәсенә дә чират җиткән. Ул аккош бәбкәсе белән бер яшьтә булса да, аңа караганда бик ябык, буйга да бик кечкенә икән.

Каз бәбкәсе бер атланып караган – булдыра алмаган, икенче атланырга уйлаган – егыла язган, өченче тапкыр атланырга теләгән икән – егылып ук киткән. Кибеттә эшләүче абыйлар каз бәбкәсе янына килеп җиткәннәр.

– Син ашны аз ашыйсың, вакытында йокламыйсың, һавада уйнамыйсың. Шуңа күрә син ябык, буең да кечкенә, шуңа күрә велосипедка аягың да җитми, – дигәннәр.

Хәзер инде: «Велосипедка аягым җитсен», – дип, каз бәбкәсе күп ашый, вакытында йоклый, саф һавада уйный икән.

*Абдулла Алиштан*

Әкият тексты белән эшләү өчен сораулар:

1) Әкиятне кем язган?
2) Әкиятнең геройлары кемнәр?
3) Каз һәм Аккошның балалары әниләреннән нәрсә алырга сорыйлар?
4) Каз бәбкәсе велосипедта йөри беләме? Ни өчен?
5) Синең велосипедка аягың җитәме?

## ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ ДӨНЬЯ

ҖИДЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

### Бакчада

*Картина белән эш*

**1. Тәрбияче алман рәссамы Винк Йоханн Амандусның (1748–1817) мәрмәр таштан эшләнгән тәлинкәдә (плитәдә) алма, груша һәм йөзем булган натюрморты белән таныштыра.**



Натюрмортны QR-код яки http://ladychef.ru/shedevry-zhivopisi/natyurmorty-s-fruktami-kartiny-izvestnyh-hudozhnikov-xvi-xviii-i-xviii-veka/ сылтамасы аша узып карарга була.

**2. Тәрбияче балаларга картинаны бергәләп карарга тәкъдим итә:**

1) елның кайсы фасылында уңыш җыеп алынуын ачыклата;
2) ни өчен алмаларның көз көне өлгерүен сораштыра, фикерләрен туплата;

3) картинада балаларның мәрмәр таштан эшләнгән тәлинкәдә (плитәдә) нәрсәләр күрүләрен ачыклый (яфраклар өстендә яткан алмалар, груша һәм ике тәлгәш йөзем, ...);
4) картинада кулланылган төсләрне билгеләтә (яшел, кызыл, сары, кара, ...);
5) бер төстәге предметларны таптыра (алмалардагы һәм грушадагы саргылт төс; йөземдәге һәм алмалардагы саргылт төс; ...);
6) предметларны алгы һәм арткы план яссылыгында билгеләтә (алгы планда мәрмәр плитәдәге нечкә сабакка уралган ике тәлгәш йөзем, бер алма, груша, яшькелт яфраклар бар, арткы планда ике алма, ... ).

**3. Тәрбияче картина буенча сораулар бирә.**

1) Бу картина сезгә ошадымы? Бигрәк тә нәрсә ошады?
2) Бу картинада нәрсәләр күрәсез?
3) Рәссам кайсы төсләрне күбрәк кулланган? Ни өчен?
4) Балалар, ничек уйлыйсыз, бу тәлинкәдә тагын кайсы җиләк-җимешләр җитми? Болар янына кайсы җиләк-җимешне куяр идегез?

**4. «Тәмле!» уены.**

Өстәл өстендәге вазага җиләк-җимеш муляжлары куелган. Чакырылган бала, өстәл янына килеп, үзе теләгән җимешне сайлап ала һәм аны ни өчен яратып ашавын сөйли. Тәме, төсе, формасы ягыннан сыйфатлый: *алма – баллы, кызыл, түгәрәк; кавын – баллы, сары, озынча.*

**5. Тәрбияче балалардан картина буенча хикәя төзетә.**

Бу картинада өч алма, бер груша, яшел һәм кара төстәге йөзем ясалган. Алар мәрмәр тәлинкәдә. Җиләк-җимеш өлгергән, матур һәм тәмле. Аларны ашыйсы килә. Рәссам алмаларны матур ясаган.

**6. Тәрбияче балаларның үзләренә яраткан бер җиләк-җимешләрен ясарга тәкъдим итә.**

СИГЕЗЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Урманда

*Картина белән эш*

**1. Тәрбияче күренекле рус рәссамы Исаак Левитанның (1860–1900) «Алтын көз» картинасы белән таныштыра.** И. Левитанның табигать күренеше остасы булуын, ел фасылларын бик оста итеп сурәтләвен әйтә һәм балалардан елның кайсы фасылы ошавын сорый.



Картинаны QR-код яки https://ru.wikipedia.org/wiki/Золотая_осень_(картина_Левитана)#/media/Файл:Levitan_Zolotaya_Osen.jpg сылтамасы аша узып карарга була.

**2. Тәрбияче балаларларга картинаны бергәләп карарга тәкъдим итә:**

1) көзнең билгеләрен санау (Агачларның яфраклары нинди? Күк йөзе, елга нинди төстә?);
2) картинадагы әйберләрне сурәтләү:
   а) җылы көзге көн;

ә) ачык зәңгәр күк йөзе һәм анда агылган ак болытлар;
б) сары агачлар уратып алган кечкенә елга, аның төсе;
в) ерактагы авыл өйләре, кырлар, урманнар;
г) картинада кулланылган төсләр (яшел, кызыл, сары, ...);
д) алтынга төренгән каеннардан яфраклар коелу күренешен тасвирлау;
е) предметларны алгы һәм арткы план яссылыгында билгеләү (алгы планда – ак каеннар, җиргә коелган кызгылт-сары яфраклар, кечкенә елга, арткы планда – ерактагы авыл өйләре, кырлар, урманнар, күк йөзе, яр буйлары, ...);
ж) бер төстәге предметларны таптыру (күк йөзе белән суның төсе; төрле агачларның яфраклары бертөсле булу, ...)

**3. Тәрбияче И. Левитанның «Алтын көз» картинасы буенча сораулар бирә:**

1) Бу картина сиңа ошадымы? Бигрәк тә нәрсә ошады?
2) Бу картинада нәрсә сурәтләнгән?
3) Рәссам кайсы төсләрне күбрәк кулланган? Ни өчен?
4) Балалар, каеннардагы яфраклар бертөсле коелганмы? Ни өчен?
5) Елга буенда утырган бер каенның яфраклары коелмаган әле. Ни өчен дип уйлыйсың?
6) Усак яфраклары нинди төстә?
7) Агачларның шәүләләре суда чагылганмы?

**4. Тәрбияче балалардан картина буенча җөмләләр төзетә:**

Бу картинада ________ ______ (**алтын көз**) сурәтләнгән.

Агачларның яфраклары ______, _______ (**сары, кызыл**).

Күк йөзе _______ (**зәңгәр**).

Җиргә _________-_______ (**кызгылт-сары**) яфраклар коелган.

**5. Тәрбияче кәрзиннән төрле яфраклар күрсәтә:**

– Көз, Көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?
Бу – каен яфрагы,
Бу – имән яфрагы,
Бу – өрәңге яфрагы,
Бу – юкә яфрагы,

Бу – усак яфрагы,
Бу – миләш яфрагы.

(Тәрбияче берничә тапкыр кабатлата.)

**6. Тәрбияче кәрзиннән балаларга саргылт-кызыл төстәге яфраклар тарата.**

Яфракларны исниләр, алардан көз исе килә. Яфракларны әкрен генә кыштырдаталар. Балалар әлеге яфракларның берсен сайлап рәсем ясыйлар, кайсы агачның яфрагы икәнен әйтәләр.

ТУГЫЗЫНЧЫ ШӨГЫЛЬ

**Композитор**

**1. Тәрбияче балаларны композитор Нәҗип Җиһанов белән таныштыра.**




Мәшһүр композитор (музыкаль әсәрләр язучы) Нәҗип Гаяз улы Җиһанов (1911–1988) 8 опера, 2 балет, 16 симфония, бик күп инструменталь әсәрләр һәм җырлар яза.

Бөек композитор бик яшьли ятим кала. Әтисе Нәҗипкә бер яшь булганда, әнисе аңа биш яшь тулганда вафат була. Шуңа күрә балалык һәм яшүсмер еллары Уральскидагы балалар йортында уза. Нәҗип үзлегеннән пианинода уйнарга өйрәнә.

1928 елда Нәҗип Җиһанов Казанга килә. Биредә аның апасы яши торган була. Ул музыка техникумына укырга керә. Нәҗип

Җиһановның композиторлык сәләтен күреп, аны Мәскәү консерваториясенең 3 нче курсына укырга алалар.

1945 елдан ул Казан консерваториясе ректоры була. Бүгенге көндә консерватория Нәҗип Җиһанов исемен йөртә.

1) Нәҗип Җиһанов кем ул? *Әйе, юк* дип җавап бирергә кирәк.
   а) биюче    ә) композитор
2) Ул нәрсә язган?
   а) шигырьләр    ә) музыкаль әсәрләр
3) Нәҗипне кем пианинода уйнарга өйрәтә?
   а) укытучы    ә) үзлегеннән
4) Ул консерваториядә кайсы шәһәрдә укый?
   а) Казанда    ә) Мәскәүдә

**2. Тәрбияче белән балалар бергә Н. Җиһановның портретын карыйлар.**

– Бу – бөек композитор Нәҗип Җиһанов. Ул бик күп музыкаль әсәрләр язган. Бу портретка карап, сез нәрсә әйтә аласыз?
– Ул нинди кеше? – Йөзе якты, күзләре уйчан, ... .
– Ул усал кешеме? – Юк, ул бик йомшак, ... .
– Музыкаль әсәрләр язган кеше ул нинди була? - ... .

**3. Тәрбияче балалар белән бергә Н. Җиһановның «Вальс»ын әлеге QR-код яки** сылтама аша узып тыңлый:

https://youtu.be/1muFcborPUg

**4. Н. Җиһановның «Вальс»ын тыңлагач, тәрбияче балалардан нинди хисләр кичергәнлекләрен сораша.**

**1)** «Вальс»ны тыңлагач, сезгә күңелле булып киттеме?
2) Әллә бераз моңсу да булып киттеме? Ни өчен?
3) «Вальс»ны тыңлагач, нәрсәләр искә төште?
4) Музыка сиңа ничек тәэсир итте?

УНЫНЧЫ ШӨГЫЛЬ

## Мультфильм

**1. Тәрбияче балаларга Г. Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый» мультфильмын карарга тәкъдим итә.**

Мультфильмны QR-код
яки https://youtu.be/Z3QRILruUlA сылтамасы аша узып карарга була.

**2. Тәрбияче мультфильмны карагач, балаларларга сораулар бирә:**

1) Вакыйга кайчан бара? (бик матур бер җәйге көндә)
2) Кем дәрес әзерләп утыра? (бер бала)
3) Баланы урамга уйнарга беренче булып кем чакыра? (Кояш)
4) Бу Кояшның сүзенә каршы бала нәрсә дип җавап бирә? («Тукта, сабыр ит, уйнамыйм, – ди, – уйнасам, дәресем кала»)
5) Өй түрендә ботакта сайраган Сандугач баланы уйнарга чакырамы? (Әйе, сандугач болай дип җавап бирә: «Әйдә тышка, күңелең ач!»)
6) Бу Сандугачның сүзенә каршы бала нәрсә дип җавап бирә?
(«Юк, сөекле Сандугачым, уйнасам, дәресем кала.
Тукта әле, бетсен дәрес, – ди, – әйтмәсәң дә уйнармын,
Син дә сайрарсың матурлап, мин авазың (сайравыңны) тыңлармын!»)
7) Шул вакытта өй түрендә бакчада кем баланы тышка уйнарга чакыра? (Алмагач Сабыйны тышка чакыра: «Әйдә тышка, күңелең ач!)
8) Бала дәресен әзерләп бетергәч, бакчага уйнарга чыгамы?
9) Ул кемнәр белән уйный? (Кояш, Сандугач, Алмагач)
10) Син урамда, ишек алдында, бакчада кемнәр белән уйныйсың? Синең дусларың бармы?

УНБЕРЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Җырлы уен «Ак калач»

**1. Тәрбияче «Ак калач» уенының барышын аңлата.**

Балалар, кулга-кул тотынышып, бер түгәрәк ясыйлар. Берсе уртага чыгып баса. Түгәрәктәге балалар, җырлый-җырлый, калач ничек пешүен, җәелү-кабаруларын кул хәрәкәтләре белән күрсәтеп, уртадагы баланы «кысып» куялар. Ул бала үз урынына берәүне сайлап чыгара да үзе түгәрәктәгеләргә кушыла һәм уен-җыр шулай дәвам итә.

«Ак калач» җырын QR-код яки https://yandex.ru/video/search?text=ак+калач+җыры+слушать сылтамасы аша узып карарга була.

**2. Сүзлек эшен башкару:**

**Калач** – күмәч, ак икмәк (булочка)
**Биек** – югары (высокий)
**Тәбәнәк** – түбән (низкий)
**Тар** – кысан (узкий)
**Киң** – иркен (широкий)
**Кабару** – күперү (подниматься)

**3. Ак калач (беренче вариант).**

Булатның туган көненә
Без пешердек ак калач:
Менә шулай ул биек,
Менә шулай тәбәнәк,
Менә шуның киңлеге.
Менә шуның тарлыгы.
Ак калач, ак калач
Теләгәнеңне сайлап кач.

**Ак калач (икенче вариант).**

Галиянең туган көненә
Без пешердек ак калач,
Менә шулай җәелгән,
Менә шулай кабарган,
Менә шулай кечкенә,
Менә шулай зур гына.
Ак калач, ак калач,
Теләгәнеңне сайлап кач!
Ак калач, ак калач,
Теләгәнеңне сайлап кач!

УНИКЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

**Зөһрә кыз**

**1. Тәрбияче балаларны «Зөһрә кыз» әкияте белән таныштыра.**

***Зөһрә кыз***

Борын-борын заманда Зөһрә исемле кыз яшәгән. Ул бик матур, бик акыллы, бик эшчән кыз булган. Кызның уңган булуына шаккатканнар. Зөһрәнең бик усал үги әнисе булган. Ул Зөһрәне яратмаган, гел ачуланган. Беркөнне үги әнисе Зөһрәгә иртәдән кичкә кадәр төпсез кисмәккә су ташырга кушкан. Кыз бик сабыр булган. Ул көянтәсе белән чиләкләрен күтәргән дә суга киткән. Көне буе кыз кисмәккә су ташыган.

Бу бик матур айлы кич булган. Яр буенда Зөһрә бер аккан суга, бер күктәге айга карап, тирән уйга чумган. Үзенең әнисенең ягымлы сүзләре исенә төшкән. Кызның битеннән кайнар яшьләре җиргә тамган.

Озак елаган Зөһрә. Ә күктән аны бер йолдыз күзәтеп торган. Бервакыт Зөһрәне шул йолдызның нурлары һавага күтәрә башлаганнар. Кыз бик курыккан. Бераздан күзләрен ачса, кыз ай уртасында утыра икән.

Әгәр сез айга карасагыз, анда көянтә-чиләк тоткан кызны күрерсез. Ә ай янында гел балкып торган йолдыз Зөһрә йолдыз дип атала.

**Кисмәк** – бочка

**2. Сорауларга җавап бирү.**

1) Зөһрә кыз кем ул?
2) Ни өчен үги әнисе Зөһрәне яратмый?
3) Тишек савытка су салсаң, ул нишли? Су өстәлгә, идәнгә ага башлыймы?
4) Төбе булмаган кисмәккә су салсаң, ул нишли?
5) Ни өчен кызның битеннән кайнар яшьләре җиргә тама? Ул кемне исенә төшерә?
6) Күктән Зөһрәне кем күзәтеп тора? Ул нишли?
7) Айга карап, Зөһрә йолдызны күргәнең бармы? Ул нинди?

**3. Тәрбияче балалардан йолдыз белән ай рәсеме ясата.**

## ТУГАН ИЛЕМ

УНӨЧЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

### Болгар

**1. Тәрбияче Болгар җирендәге тарихи һәйкәлләрнең рәсемнәрен күрсәтә бара, шигырьне укый.**

***Болгарда***

Әнием белән икәү
Изге Болгарга бардык.
Ак пулат, Кара пулат –
Барысын да карадык.

Якында гына музей
«Икмәк музее» диләр.
Анда тегермән дә эшли
Иссәләр көчле җилләр.

Су тегермәнен дә күрдем
Ул да он ясый икән.
Пешекчеләр ул оннардан
Икмәк пешерә икән.

«Болгар бездән ерак», – диеп
әни әйткән иде дә.
Кама буйлап бик тиз генә
Әйләнеп кайттык менә.

**2. Тәрбияче җөмләләр әйтә һәм балаларга төшеп калган сүзләрне өстәп әйтүне сорый.**

Болгар борынгы _______ (шәһәр)

Болгар _______ елгасы буенда урнашкан. (Кама)

Болгарда Ак һәм _____ пулатлар бар. (кара)

Мин җил һәм ______ тегермәннәре күрдем. (су)

Пешекчеләр оннан _______ пешерә. (икмәк)

**3. Борынгы Болгар сурәтләнгән фотосурәт ярдәмендә Болгар турында балалар бергәләп текст төзиләр.**

Бу фотосурәтне QR-код яки https://s.tnv.ru/resize_cache/38331/8a9aedecc3d17a817cae733f3a9cbc01/iblock/6dc/volga_bulgarlari_tataristan_800x445.jpg сылтамасы аша узып карап була.

УНДҮРТЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

**Шүрәле Кырлайда**

**1. Тәрбияче «Шүрәле» әкиятенең беренче юлый укый.**

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр...

**«Шүрәле» мультфильмын күрсәтә.**

Мультфильмны карар өчен QR-кодны яки https://youtu.be/LDJIle9xCvw сылтамасын файдаланырга була.

**2. Тәрбияче балаларга Былтыр белән Шүрәленең рәсемен күрсәтеп, Былтырның Кырлай дигән авылда яшәвен әйтә.** Кырлай авылының Татарстан Республикасының Арча районында урнашуын әйтә.

**3. Тәрбияче әкиятне кычкырып укый.** Балалар белән бергә сорауларга җаваплар бирәләр.

Йоклар алдыннан Арслан әнисенең әкиятләрен тыңларга ярата. Әкият тыңлаганда, йокыга китә. Ул йоклаганда да әкияттән аерылмый. Әкият аның төшендә яши. Әнисенең тавышы инде әкрен генә ишетелә.

Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;
Урта бармак буйлыгы бар маңгаенда мөгезе.

Арслан йокы аралаш елмая. Бу әкият аңа таныш: Шүрәле турында сөйли әнисе. Әнә ул Арсланга кул болгый. Күзләре ялтырый, үзе йонлач. Бармаклары озын, чөнки ул урманда адашкан юлчыларны кытыклап уйнарга ярата.

– Син Сабантуйга кайтырга телисе икән, – ди Шүрәле Арсланга.

– Кайтам. Минем дә батыр буласым килә!

Арслан Шүрәледән курыкмый. Үз төшендә үзе нигә курыксын?! Шүрәле бит аның төшенә керде.

– Мин сине Батырлар иленә кертмим, – диде Шүрәле һәм, бармакларын сузып, Арсланга таба килә башлады.

Арслан чигенергә уйламады да.

– Анда минем бабайлар яшәгән. Ул – минем илем! – дип кычкырды малай.

– Бабаңның исемен беләсеңме соң?

– Белмичә. Аның исеме – Былтыр!

Шүрәлене ай күрде, кояш алды. Былтырның оныгыннан ничек качмасын?! Былтыр бит ул – кайчандыр урманга баргач, аның бармакларын бүрәнә ярыгына кыстырган батыр.

*Ркаил Зәйдулладан*

1) Шүрәле кайда яши?
2) Шүрәле нинди?
3) Арслан кая кайтырга тели?
4) Шүрәле ни өчен кача?

**4. Тәрбияче балаларга карандаш белән ясалган Шүрәле рәсемен тарата, балалар аны буйыйлар.**

## УНБИШЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

### Хайваннар турындагы әкиятләр, җырлар

**1. Тәрбияче хайваннар турында язылган әкиятләрнең бик күп булуын әйтә. Мисаллар китерә.** Әкияттән өзекне укый.

Куян башына эшләпә үреп киде һәм, култык астына зур дәфтәр кыстырып, күмер карандаш алып, Аю алдына килеп басты:

– Мин әзер, Аю ага!

– Әзер булсаң, киттек, – диде Аю.

Алар ап-ак кәүсәле зифа агач янына килеп туктадылар.

– Мин үзем яши торган шушы урмандагы агачларның һәммәсе белән дә аерым-аерым танышырга телим. Бу эшне синнән башларга булдым, – диде Аю, әлеге агачка карап.

Ап-ак кәүсәле агач, башын ия-ия, яшел яфраклы ботакларын тибрәндереп, җавап бирде:

– Бик яхшы, – диде.
– Исем-фамилияң ничек? – дип сорады Аю.
– Каен Каюмов, – диде әлеге ак кәүсәле агач.
– Яз, – диде Аю, Куянга борылып.

Куян яфрактан тегелгән дәфтәргә күмердән ясалган карандаш белән ниндидер билгеләр төшерде.

*Гариф Галиевтән*

1) Әкиятнең геройлары кем?
2) Урманда тагын нинди хайваннар яши?
3) Синең исем-фамилияң ничек?

**2. Тәрбияче рәсемнәр ярдәмендә урманда үсә торган агачлар (каен, нарат, чыршы, усак һ.б.) турында сөйли.** Агач яфракларын (яки рәсемнәрен) күрсәтеп, төрле агачларны танырга өйрәтә.

**3. Бергәләп җыр өйрәнү.** Әлеге шөгыльдә, сайлап алу өчен, өч җыр тәкъдим ителә.

1. ***Дускаем – Акбаем***

Бар минем дускаем, дускаем –
Нәни йомшак маэмаем, Акбаем.
Мин аны бик яратам, яратам,
Тәмле-тәмле конфетлар ашатам.

Мин аны чакырсам, ул чаба,
Минем белән ул бергә шаяра.
Тик Акбаем сөйләшми, сөйләшми,
Мин көтеп-көтеп карыйм, ул дәшми.

Бу җырны QR-код яки https://page.ligaudio.ru/mp3/%D0%B0%D0%BA%D0%B1%D0%B0%D0%B9 сылтамасы аша узып тыңларга була.

2. **Арыслан баласы һәм ташбака ничек җыр җырлаган**

Мин кояшта ятамын,
Кояшка күз атамын.
Мин ятам, гел ятам,
Һәм кояшка күз атам.

Мөгезборын-рын уза,
Крокодил-дил-дил йөзә.
Мин генә ятамын,
Кояшка күз атамын.

Арыслан килде тагын,
Селкетә колакларын.
Мин ятам, мин тормыйм
Арысланга карамыйм.

Бу җырны QR-код
яки https://vimeo.com/107858855 сылтамасы аша
узып тыңларга була.

3. ***Куяннар***

*Ф. Шәймәрданова музыкасы,*
*татар халык сүзләре*

| | |
|---|---|
| Ап-ак куян утыра, | |
| Колакларын селкетә. | |
| Менә шулай, менә шулай | *кулларын баш өстенә куеп,* |
| Колакларын селкетә. | *колаклар итеп селкиләр* |
| Аңа тик тору кыен, | |
| Җылыта ул тәпиен. | |
| Менә шулай, менә шулай | *кулларын бер-берсенә* |
| Җылыта ул тәпиен. | *ышкып җылыталар* |
| Куян тик торса туңа, | |
| Сикергәли ул шуңа. | |
| Менә шулай, менә шулай | *бер урында сикерәләр* |
| Сикергәли ул шуңа. | |

Бу җырны QR-код
яки https://youtu.be/7pxAnzeP-2s сылтамасы аша
узып тыңларга була.

## УНАЛТЫНЧЫ ШӨГЫЛЬ

### Кошлар турындагы әкиятләр, җырлы уеннар

**1. Тәрбияче әкиятне укый.** Бергәләп сорауларга җавап бирәләр.

***Әтәч ни өчен өч вакыт кычкыра?***

Борын-борын заманда Әтәчнең йон-каурыйлары бик тә зиннәтле, салават күпере кебек гүзәл булган.

Ә Тавис кош ул чакта гади генә киенеп йөргән. Мактанчык Әтәч аннан көлгән. Шуннан Тавис бер хәйлә уйлаган һәм Әтәч янына килгән.

Тавис Әтәчкә әйткән: «И генерал әфәнде, и гүзәл Әтәчкәй, ярдәм сорап килдем сиңа. Өйләнергә исәбем бар, киемеңне биреп торчы миңа. Әгәр анда озаграк торсам, таң атуга, мине чакырырсың. Тавышың бик көчле һәм матур. «Китереп бир!» – дип кычкырырсың. Иртә белән кайтмасам, көндез кычкырырсың, көндез күренмәсәм, кич җиткәчтен кычкырырсың».

Әтәч киемнәрен салып биргән.

Иртәгесен Әтәч: «Китереп бир! Китереп бир!» – дип кычкырган. Тавис китермәгән. Төш вакытында тагын кычкырган Әтәч, ә Тавис күренмәгән. Кич җиткәч тә кычкырган. Тавис юк та юк икән.

Шуннан бирле Әтәч көн саен Тависка: «Китереп бир!» – дип кычкыра. Тавис килми дә килми.

1) Бу әкиятнең геройлары кемнәр?
2) Әтәч белән Тавис йорт кошларымы?
3) Тавис нинди?

**2. Тәрбияче төрле кошларның рәсемнәрен күрсәтеп, кошларны танырга өйрәтә.**

**3. Бу шөгыльдә ике уен тәкъдим ителә.**

1. **Тәрбияче «Чума үрдәк, чума каз» уенын уйнарга тәкъдим итә.**

Балалар бер-берсенә карап (ике саф булып) тезелешеп басалар. Бер бала так кала, ул балаларга карап баса. Балалар бала исемен әйтеп җырлыйлар. Җыр бетүгә, так калган бала саф арасыннан үтә, үзенә пар таба, артка барып басалар. Ялгыз калган бала алга чыгып баса, уен дәвам итә.

Чума үрдәк, чума каз,
Чума үрдәк, чума каз,
Тирән күлне ярата шул, ярата.
Тирән күлне ярата шул, ярата.
Булат үзенә иптәш сайлый
Булат үзенә иптәш сайлый,
Ул Алияне ярата шул, ярата.
Алияне ярата шул, ярата.

Җырны җырлаганда QR-кодны яки https://youtu.be/Mh9Oiaz5SEo сылтамасын файдаланырга була.

2. **«Кошлар» уены.**
*Балалар идәндә чүгәләп утыралар.*

| | |
|---|---|
| Нәни кошлар уяндылар, | *әкрен генә торалар* |
| Канатларын кагындылар. | *кулларын як-якка селкиләр* |
| Чырык-чырык чыркылдап, | *чәбәклиләр* |
| Төрле якка таралдылар. | *төрле якка таралышалар.* |

## УНҖИДЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

### Татарлар

**1. Тәрбияче шигырьне укый.** Сорауларга җавап бирәләр.

***Яхшы бел***

Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле затлы тел.

Татарчасы – туган тел,
Безгә газиз булган тел.
Әти-әни, әби-бабай,
Сине сөя торган тел.

Тел кешене дус итә,
Бер-берсенә беркетә.

Бел, балам, син рус телен
һәм онытма үз телең!

*Шәйхи Маннурдан*

1) Татар телендә кемнәр сөйләшә?
2) Туган тел нинди тел ул?

**2. Бу шөгыльдә ике җыр тәкъдим ителә.**

1. **Тәрбияче балаларга «Татар теле – туган телем» җырын тыңлата.** Җырны бергәләп җырларга өйрәнәләр.

***Татар теле – туган телем***

*Нәҗип Мәдияров сүзләре,*
*Виталий Агаповк музыкасы*

Татар теле минем, туган телем,
Сөйләшүе рәхәт ул телдә.
Шул тел белән көйлим...
Шул тел белән сөйлим
Милләттәшем булган һәркемгә.

Татар теле минем, туган телем,
Бәхетем ул, сүнмәс шатлыгым.
Шул тел белән уйлыйм,
Шул тел белән җырлыйм,
Тоям аның һәрчак сафлыгын.

Татар теле минем, туган телем,
Изгелекләр тулы бу телдә.
Аны якын күреп,
Сөйләшүдән сөеп
Тыя алмый мине беркем дә.

Татар теле минем, туган телем,
Саклый аны батыр милләтем.
Әби-бабам теле,
Ата-анам теле,
Күңелем тулы аңа хөрмәтем.

Бу җырны QR-код
яки https://power.gybka.com/q/балалар+җыры/
сылтамасы аша узып тыңларга була.

2. ***Туган телем***

*Энҗе Мөэминова сүзләре*

Балам! – диеп,туган телдә
Эндәшә миңа әткәм.
Әнием! – дип, әнкәемә
Мин туган телдә әйтәм.

Кушымта:

Дөньяда иң-иң матур ил
Ул – минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел
Ул – минем туган телем.

Туган телемдә сөйләшеп
Яшим мин Туган илдә
Туган ил дигән сузне дә
Әйтәм мин туган телдә.

Кушымта.

Бу җырны QR-код
яки https://muzebra.net/song/туган%20телем сылтамасы аша узып тыңларга була.

## УНСИГЕЗЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

### Руслар

**1. Тәрбияче текстны укый.**

Россиядә 190 нан артык милләт вәкиле яши. Руслар – Россиядәге иң күпсанлы халык. Без рус шагыйрьләре һәм язучыларыннан Александр Пушкин, Николай Носов, Агния Барто, Самуил Маршак, Сергей Михалков әсәрләрен яратып укыйбыз. Аларны татар теленә дә тәрҗемә иткәннәр.

**2. Тәрбияче «Йомры икмәк» әкиятен укый.**

### *Йомры икмәк*

Әби белән бабай бик тату яшәгәннәр. Бервакыт бабай әбигә:

– Карчык, икмәк пешер әле? – дигән.

– Нәрсәдән пешерим соң, он юк бит.

– Эх, карчык, әрҗә төбеннән кырып бераз җыелмасмы?

Әби бер-ике уч он җыйган. Ул шул оннан йомры икмәк пешергән дә тәрәзә төбенә суытырга куйган.

Икмәк тәрәзә төбеннән урамга тәгәрәп төшеп, юл буйлап тәгәрәп киткән. Икмәк юл буйлап тәгәрәп барганда, каршысына бер куян килеп чыккан:

– Икмәк, Йомры икмәк, мин сине ашыйм! – дигән аңа Куян.

– Син мине ашама, Кылый куян, мин сиңа җыр җырлармын, – дигән дә шунда ук җырларга тотынган.

– Мин – Йомры икмәк, Йомры икмәк. Мин бабайдан да качтым, мин әбидән дә качтым, синнән дә, Куян, кыен булмас качуы! – дигән дә, үз юлына тәгәрәп китеп барган.

Йомры икмәк һаман тәгәрәвен белгән. Менә бервакыт аның каршысына бер бүре килеп чыккан.

– Йомры икмәк, Йомры икмәк, мин сине ашыйм!

– Син мине ашама, Соры бүре, мин сиңа җыр җырлармын.

– Мин – Йомры икмәк, Йомры икмәк. Мин бабайдан да качтым, мин әбидән дә качтым, мин куяннан да качтым, синнән дә кыен булмас качуы! – дигән дә алга тәгәрәгән.

Йомры икмәк тәгәрәгән дә тәгәрәгән. Менә бервакыт аның каршына бер аю килеп чыккан.

– Йомры икмәк, йомры икмәк, мин сине ашыйм!

– Кайда ул сиңа, Кыйшык аяк, мине ашарга! Мин – Йомры икмәк, Йомры икмәк. Мин бабайдан да качтым, мин әбидән дә качтым, мин куяннан да качтым, мин бүредән дә качтым, синнән дә, аю, кыен булмас качуы! – дигән һәм йомры икмәк тагын да алга таба тәгәрәп киткән.

Йомры икмәк тәгәрәгән дә тәгәрәгән, аның каршысына бер төлке килеп чыккан:

– Исәнме, Йомры икмәк, син нинди гүзәл икән?! Аңа каршы йомры икмәк җырлый башлаган:

– Мин – Йомры икмәк, Йомры икмәк. Мин бабайдан да качтым, мин әбидән дә качтым, мин куяннан да качтым, мин

бүредән дә качтым, мин аюдан да качтым, синнән дә, төлке, кыен булмас качуы!

– Нинди яхшы җыр! – дигән Төлке.– Тик мин, Йомры икмәк, картайдым инде, бик начар ишетәм; минем борыным өстенә утырып тагын да бер генә җырлап күрсәт әле. Кычкырыбрак җырла.

Йомры икмәк төлкенең борын өстенә менеп утырган да шул ук җырны кабатлаган.

– Рәхмәт, Йомры икмәк, яхшы җыр. Мин тагын да тыңлар идем. Минем телем өстенә утырып соңгы тапкыр җырлачы! – дигән Төлке һәм телен чыгарган.

Йомры икмәк уйлап-нитеп тормаган, төлкенең тел өстенә сикергән, ә төлке аны шунда ук «һам!» итеп йотып та җибәргән.

Түбәндәге сорауларга әйе, яки юк дип кенә җавап бирергә кирәк.

1) Йомры икмәкне әби пешерәме?
2) Йомры икмәкне әби өстәлгә куямы?
3) Йомры икмәккә беренче булып бүре очрыймы?
4) Йомры икмәкне аю ашыймы?
5) Төлке йомры икмәкнең теленә утыруын сорыймы?

**2. Балалар үзләре яраткан рус халык әкияте буенча рәсем ясый.**

# ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

## УНТУГЫЗЫНЧЫ ШӨГЫЛЬ

### Сабантуй

**1. Тәрбияче балаларга шигырьне укый.**

***Сабан туе җыры***

Сабан туе – хезмәт туе,
Шатлык һәм бәхет туе шул.
Уйнап-биеп, җырлап-көлеп
Бәйрәм итик көн буе.

Шау-гөр килә киң болыннар,
Кырлар һәм су буйлары шул.
Котлы булсын, авылдашлар,
Ямьле Сабан туйлары!

Бәйрәм итик шатланышып,
Туганнар, бергә-бергә шул.
Безнең бергә булуыбыз
Китсен бөтен гомергә.

*Мөхәммәт Садри*

**2. Сорауларга җавап бирү.**

1) Татарларның иң күңелле бәйрәме – Сабантуй кайчан үткәрелә? (*җәй көне, июнь аенда, язгы кыр эшләре беткәч*)
2) Синең бу бәйрәмдә булганың бармы? Берәр уенда катнаштыңмы?
3) Сабантуйда нишлиләр? Нинди уеннар үткәрәләр?
4) Ат чабышын күргәнең бармы? Иң арттан килгән чабышчыга нәрсәләр бирәләр?

**3. Рәсемнәр ярдәмендә колгага менү, капчык сугышы, капчык киеп йөгерү, чүлмәк вату уеннарын искә төшерү.**

**4. Күренекле татар рәссамы Лотфулла Фәттаховның «Сабантуй» (1957) картинасы буенча эш.**



Картинаны QR-код
яки https://upload.wikimedia.org/wikipedia/tt/c/c9/Fattaxov_Sabantuy.jpg сылтамасы аша узып карарга була.

1) Алгы планда бәйрәмчә киенгән балалар, өлкәннәр, киң мәйдан, ак сакаллы бабай, көрәш сурәтләнгән.
2) Арткы планда баганада эленгән чиккән сөлгеләр, батырга биреләчәк тальян гармун, көч биреп торучы ак шәлле әбиләр, башларына түбәтәй кигән абыйлар, табигать күренеше (җылы матур көн, каен агачының күләгәсе).
3) Рәссам кайсы төсләрне күбрәк кулланган? Ни өчен?

**5. Лотфулла Фәттаховның «Сабантуй» картинасы буенча текст төзү.**

Җәйге җылы көн. Кешеләр Сабантуй бәйрәменә килгәннәр. Алар бәйрәмчә киенгәннәр. Мәйданда батырлар көрәшә. Ак сакаллы бабай тәртип саклый. ... .

ЕГЕРМЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Милли ризыклар

**1. Тәрбияче балаларга шигырьне бер кат укып чыга.**

***Кунаклар***

Без әзерлибез табын
Китереп бөтен ягын.
Уртага куйдык чәкчәк,
Чәкчәк янында – чәчәк
Бавырсак һәм кош теле.
Ризыклар төрле-төрле –
Сумса, бәлеш, өчпочмак,
Гөбәдия һәм коймак.
Һәркемгә чыгар өлеш,
Бар кыстыбый һәм бәлеш.

*Шәүкәт Галиев*

**2. Сорауларга җавап бирү.**

1) Өстәл янына утыргач, бер-беребезгә кайсы тылсымлы сүзләрне әйтәбез? (Ашларыгыз тәмле булсын!)
2) Яраткан ризыгың нәрсә?
3) Ул ризыкларны сезгә кем пешерә?
4) Бу шигырьдә нинди ризыклар турында әйтелә? (Тәрбияче шигырьне кабат укый)
5) Бу ризыклар арасыннан кайсысы сиңа күбрәк ошый? Ни өчен?

**3. Ризыкның исемен әйт.**

1) Бу ризыкны пешерер өчен, он, ит, бәрәңге, суган, тоз, май кирәк. Кайсы ризык турында сүз бара? (өчпочмак, бәлеш)
2) Бу ризыкны пешерер өчен, он, май, бал, йомырка, шикәр комы кирәк. Кайсы ризык турында сүз бара? (чәкчәк)

**4. Коймакка реклама ясa.**

Кыстыбый – тәмле ризык. Бу ризыкны пешерер өчен, он, май, йомырка, бәрәңге, тоз кирәк.

Коймак – ... .

**5. «Кем зирәк, әйт тизрәк!» уены.**

Йомырка белән онны
Бутап камыр басканнар.
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар. *(Өчпочмак)*

Чыж иттереп саласың,
Бик тиз генә аласың.
Балга манып кабасың.
Ул нәрсә? *(Коймак)*

Утырсам да мин менә
Тыйнак кына, тик кенә.
Эчем тулы ит кенә,
Май, бәрәңге, суган гына. *(Бәлеш)*

Камыр эчендә бәрәңге,
Йә, уйлап кара әле. *(Кыстыбый)*

Иттән генә торам мин,
Камырга да төрәләр,
Майга чумып чыгам мин.
Тәлинкәгә өяләр. (Пәрәмәч)

Вак-вак кына итеп кисеп,
Өяләр аны таудай!
Чак-чак кына алып, өзеп
Аша, дустым, син шулай. *(Чәкчәк)*

ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

**Милли киемнәр**

**1. Тәрбияче шигырьне ике тапкыр укып чыга һәм балалар белән бергәләп сорауларга җавап бирәләр.** (Өстәлдә түбәтәй һәм калфак кигән ике курчак тора. Тәрбияче балаларны алар белән таныштыра).

***Кәләпүшем, кәләпүш***

Йөзләремә килешәсен
Кайлардан гына белгән,
Туган көнгә дәү әтием
Кәләпүш алып килгән.

Кәләпүшемне кидем мин,
Көзге каршына килдем.
– Менә шушындый була ул –
Татар малае! – дидем.

Инде җырлый да беләм мин,
Инде бии дә беләм.
Сәхнәләрнең түрендә мин
Кәләпүшкәем белән.

Әнием дә бик сөенде,
Кочаклап алып сөйде.
Котлы булсын кәләпүшең,
Бигрәк килешә, диде!

*Резеда Вәлиева*

1) Кәләпүш нәрсә ул?
2) Ул нинди төстә була? (яшел төстә, чигүле була)
3) Синең чигүле түбәтәең бармы?
4) Аны сиңа кем алып бирде?
5) Малайның туган көненә кем кәләпүш бүләк итә?
6) Әнисе дә бик сөенә һәм малайга нәрсә ди?

**2. Тәрбияче шигырьне ике тапкыр укып чыга һәм балалар белән бергәләп сорауларга җавап бирәләр.**

***Энҗе-мәрҗән калфагым...***

Дәү әнием энҗе калфак
Бүләк итте үземә,
Энҗе калфак, үзе ап-ак,
Бик килешә йөземә.
Энҗе-мәрҗән калфагыма
Йөрим сөенеп кенә,
Сәхнәләргә чыгып җырлыйм,
Калфаклар киеп кенә.

*Резеда Вәлиева*

1) Нәрсә ул калфак?
2) Синең чигүле калфагың бармы?
3) Ул нинди төстә?

4) Дәү әнисе оныгына нинди калфак бүләк итә?
5) Кыз сәхнәләргә энҗе-мәрҗәннән эшләнгән калфак киеп чыгамы?
6) Балалар, курчакның калфагы энҗе-мәрҗәннән эшләнгәнме?

**3. Тәрбияче малайларга – кәләпүш, кызларга калфак рәсемнәре, милли бизәкләр тарата.** Балаларга кәләпүшне, калфакны бизәргә тәкъдим итә.

**4. Табышмакның җавабын тап.**

Әнием ак сәйлән тезеп
Чиккән яшел бәрхетне.
Ул үзем кебек бәләкәй,
Ә исеме … . *(Түбәтәй)*

**Сәйлән** – бисер

ЕГЕРМЕ ИКЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Татар халык биюләре

**1. Тәрбияче шигырьне ике тапкыр укып чыга һәм балалар белән бергәләп сорауларга җавап бирәләр.** (Кызлар, малайлар, кара-каршы басып, музыка астында татар халык биюен бииләр)

***Әнисә***
*(Бию такмагы)*

Тыпыр-тыпыр биергә
Тимер идәннәр кирәк;
Тимер идәннәр өстенә
Хәтфә паласлар кирәк.

Хәтфә паласлар өстенә
Имән өстәлләр кирәк;
Имән өстәлләр өстенә
Көмеш табаклар кирәк.

Көмеш табаклар эченә
Хөрмә-җимешләр кирәк;
Хөрмә-җимешләр ашарга
Алтын кашыклар кирәк.

Алтын кашыклар тотарга
Кара кашлы кыз кирәк;
Кара кашлы кыз каршына
Батыр егетләр кирәк.

**Хәтфә** – бархатный, плющевый
**Табак** – большая чаша

Җырны QR-код яки https://power.gybka.com/song/58092606/Balalar_yrlyj_-_nis_tatar_halyk_yry/ сылтамасы аша кереп карарга була.

**Сорауларга җавап бирү**

1) Син биергә яратасыңмы?

2) Нинди биюләр беләсең?

3) Тыпыр-тыпыр биер өчен, нинди идәннәр кирәк? (нык идәннәр кирәк)

4) Идәннәргә тагын нәрсәләр җәяргә кирәк? (хәтфә паласлар (келәмнәр)

5) Хәтфә паласларга өстәлләрне куеп буламы?

6) Көмештән эшләнгән табаклар нәрсә өчен кирәк?

7) Табакка нинди җимешләр салганнар? Аларны нәрсә белән ашыйлар?

8) Матур кызлар, батыр малайларның бергәләп биегәннәрен карыйк әле.

Биюне карау өчен QR-кодны яки https://youtu.be/ZCvgCxiSr3A сылтамасын файдаланырга була.

**2. Тәрбияче шигырьне ике тапкыр укып чыга һәм балалар белән бергәләп сорауларга җавап бирәләр.**

***Бииләр итек, читекләр***

Гармун уйныйм, гармун уйныйм,
Һаман гармун уйныйм мин,
Остарып җиткәч, барсын да
Биетергә уйлыйм мин.

Учларыңны шакылдатып,
Чәчләреңне сыпыр да
Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр,
Тыпыр-тыпыр тыпырда.

Әй, бии итек, читекләр!
Әй, уйныйм мин, уйныйм мин,
Минем кебек шәп гармунчы
Юктыр диеп уйлыйм мин!

*Шәүкәт Галиев*

**Сорауларга җавап бирү.**

1) Читек нәрсә ул?
2) Ул нәрсәдән эшләнгән?
3) Читек нинди төстә була?
4) Курчакларның читекләре бармы? (тәрбияче ике курчакны күрсәтә)
5) Кем ул гармунчы?
6) Гармунчы нәрсәдә уйный?
7) Гармунчының гармунда уйнаганын күргәнең бармы? Ул ничек итеп уйный?

**3. Тәрбияче белән балалар бергә татар халык биюен бииләр.**

**4. Табышмакның җавабын тап.**

Телләре бик күп булса да,
Һәркем аңлый, үз итә.
Елата да, җырлата да,
Кирәк икән – биетә. *(Гармун)*

ЕГЕРМЕ ӨЧЕНЧЕ ШӨГЫЛЬ

## Тукай геройлары

**1. Тәрбияче Габдулла Тукайның фотосын күрсәтеп, шагыйрь турында кыска гына әңгәмә үткәрә.**



Шуннан соң тәрбияче шигырьне укып чыга. Балаларга Шүрәле, Су анасы, карлыгач, әтәч рәсемнәрен күрсәтә.

***Тукай геройлары янәшә***

Шигырьләре һәм җырлары белән
Тукай безне үзенә дәшә.
Геройлары аның әйтерсең лә
Безнең белән яши янәшә.

Җәй көнендә урман аланында
Көтеп тора кебек Шүрәле.
Кытыкламый үзе, бик тәртипле,
Әйтә кебек: «Әйдә, көл әле!»

Их, дуслашыр идем аның белән,
Җыяр идем гөмбә, җиләген.
Ул бит белә кайда күбрәк үсә,
Тизрәк тулыр иде чиләгем.

Су анасы килеп чыгар төсле,
Су кергәндә инеш буенда.
Ефәк кебек чәчен җил туздыра,
Алтын тарак аның кулында.

Күз дә алмый карап торыр идем
Рәхәт итеп чәчен таравын.
Озын толымымны тарар өчен
Сорап торыр идем тарагын.

Әллә инде карлыгачы кайткан,
Тәрәз шакый язгы иртәдә.
Әтәче дә: «Уяндыңмы?» – диеп
Аваз сала кебек киртәдә.

Шагыйремнең геройлары кайтса,
Тормас идем бер дә аптырап.
Шүрәлеләр белән уйнар идем,
Куркып калмас идем калтырап.

*Гүзәлия Галләмова*

**2. Тәрбияче төркемнән ике баланы сайлап ала.** Берсенә Шүрәле, икенчесе Су анасы рәсемен тапшыра, аларны балалар каршына урындыкка утырта. Тәрбияче китап күрсәтә, Шүрәле белән Су анасы ролендәге балалар тәбиячене күрмиләр. Алар башка балаларга сораулар биреп, тәрбияченең нинди предмет күрсәткән булуын әйтергә тишләр.
Ул предмет зурмы? Аны ашыйлармы? кебек сораулар бирергә тәкъдим итelә.

**3. Тәрбияче балалардан: «Сез Габдулла Тукайның карлыгач, әтәч турындагы әсәрләрен беләсезме?» – дип сорый. «Әтәч илә күке», «Әтәч илә энҗе бөртеге» кебек мәсәлләре булуын әйтә.** Тәрбияче балаларга Г. Тукайның «Карлыгач» шигырен тыңлата. Балалар белән бергәләп сорауларга җаваплар бирәләр.

Шигырьне QR-код яки https://power.gybka.com/song/164093898/Tukaj_-_Karlygach/ (Р. Зәкиева) сылтамасы аша узып тыңларга була.

1) Карлыгач кайда яши?
2) Ул ояны нәрсәдән ясый?
3) Карлыгач балаларына нәрсәләр ашата?

**4. Тәрбияче мәсәлне укый.**

***Әтәч илә Күке***

– И сөекле Әтәч, нинди матур сайрыйсың!

– Ә син, Күкеҗан, бигрәк моңлы, бигрәк күңелле җырлыйсың! Синдәй сайраучы бөтен дөнья урманнарында да булмас. Аһ! Синең җырлавыңны тыңлап кына торыр идем. Менә, билләһи, ант итәм. Әгәр син сайраудан туктасаң, тагы кайчан гына сайрый башлар икән дип көтәмен. Минемчә, синең тавышың янында Сандугач тавышы бөтенләй югаладыр.

Бу макташуны читтән тыңлап торган Чыпчык, Әтәчнең сүзен бүлеп:

– Сез, дуслар, бер-берегезне макташып киерелсәгез дә, музыкаңыз һаман борынгыдыр, – диде.

*Габдулла Тукай*

**5. Сорауларга җавап бирү.**

Тәрбияче QR-код яки https://zvukipro.com/35-zvuki-i-kukarekane-petuha.html сылтамасы аша узып, әтәч кычкыруын тыңлата.

– Әтәч сайрый беләме?

Тәрбияче QR-код яки https://zvukipro.com/45-zvuki-kukushki.html сылтамасы аша узып, күке тавышын тыңлата.

– Күке җырлый беләме?

Тәрбияче QR-код
яки https://zvukipro.com/27-zvuki-peniya-solovya.html сылтамасы аша узып, сандугач сайравын тыңлата.

– Өч кошның кайсысы матур сайрый?
– Әтәч белән күке бер-берсен мактыйлар. Алар дөресен әйтәләрме?
– Габдулла Тукайның геройлары безне нәрсәгә өйрәтә?
– Былтыр нинди?
– Су анасы малайга нәрсәнең начар булуын аңлата?

**6. Тәрбяче балаларга Г. Тукайның «Кызыклы шәкерт» шигыре буенча төшерелгән мультфильмны күсәтә.**

Мультфильмны карау өчен QR-код
яки https://youtu.be/IqhOG3g1kb0 сылтамасы аша узарга кирәк.

– Балалар, тиздән Сез дә укучылар булырсыз, мәктәпкә китәрсез. Сез тырыш, гадел, акыллы укучылар булырсыз.

**«Өйрәтәләр мәктәпләрдә» җырын бергәләп өйрәнәләр.**

***Өйрәтәләр мәктәпләрдә***

*Михаил Пляцковский сүзләре*
*Владимир Шаинский музыкасы*

Каләм тотып кулларга, хәрефләрне язарга
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.
Тапкырларга, бүләргә, нәниләрне сөяргә
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.

Бишкә бишне кушарга, хәрефтән сүз язарга
Өйрәтәләр мәктәпләрдә мәктәпләрдә.
Белер очен бик күпне, яратырга китапны
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.

Таңнар ничек атканны, кояш ничек батканны
Өйрәтәләр мәктәпләрдә мәктәпләрдә.
Табарга утрауларны,биек-биек тауларны
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.

Өтер белән ноктаны кайчан кайда куйганны
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.
Дуслык кадерен белергә, сузылсын дип гомергә
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.

Җырны QR-код
яки https://page.ligaudio.ru/mp3/%D3%A9%D0%B9%D1%80%D3%99%D1%82%D3%99%D0%BB%D3%99%D1%80%20%D0%BC%D3%99%D0%BA%D1%82%D3%99%D0%BF%D0%BB%D3%99%D1%80%D0%B4%D3%99 сылтамасы аша узып тыңларга була.

# ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия. – Казан: РИЦ, 2011. – 560 б.

Бикмуллина А.Ф. Йолдызлар шулай куша: балалар өчен хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. – 63 б.

Галиев Г. Аю агачлар белән... сөйләшә: Әкият / Как Медведь с деревьями... разговаривал: Сказка. – Казан: Мәгариф, 2003. – 40 б.

Галиев Ш. Шәвәли шуклыгы: балалар өчен шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 166 б.

Галләмова Г.Х. Җиләкле җәй: балалар өчен шигырьләр. – Казан: Рухият, 2012. – 40 б.

Зәйдулла Р.Р. Сабантуй сөлгесе: Балалар өчен хикәя. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 38 б.

Исхакова-Вамба Р.А. Уен җырлары. – Барда, 1994. – 112 б.

Йолдыз. Колаклы коймаклар: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 63 б.

Миннуллин Р.М. Безнең авыл зоопаркы: балалар өчен шигырьләр һәм җырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 80 б.

Миннуллин Р.М. Күңелле тәнәфес: балалар өчен җырлар – Казан: Татар. кит. нәшр., 2020. – 173 б.

Сафин Ф.М. Әйдәгез, дуслашыйк!: шигырьләр, шигъри календарь. – Казан: Рухият, 2018. – 56 б.

Татар халык җырлары / Төз. Р. Шакирова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 238 б.

Туганнан алып мәктәпкәчә: Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы / Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясендә. – Казан: ХӘТЕР, 2016. – 357 с.

Фәрхетдинова Л.Н. Өч алма. – Казан: Рухият, 2019. – 48 б.

ЭЧТӘЛЕК

Аңлатма язуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны сәнгати-эстетик яктан үстерү . . . 4
Мин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Беренче шөгыль. Җырлар: Иң кадерле кешеләр. . . . . . . . . 5
Икенче шөгыль. Җырлар: Дүрт аяклы дусларыбыз . . . . . . 10
Өченче шөгыль. Уеннар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Дүртенче шөгыль. Төрле кул эшләре турында мәгълүмат бирү 13
Бишенче шөгыль. Шагыйрьләр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Алтынчы шөгыль. Әкият укыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Әйләнә-тирә дөнья . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Җиденче шөгыль. Бакчада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Сигезенче шөгыль. Урманда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Тугызынчы шөгыль. Композитор. . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Унынчы шөгыль. Мультфильм . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Унберенче шөгыль. Җырлы уен «Ак калач». . . . . . . . . . 31
Уникенче шөгыль. Зөһрә кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Туган илем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Унөченче шөгыль. Болгар. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Ундүртенче шөгыль. Шүрәле Кырлайда . . . . . . . . . . . . 35
Унбишенче шөгыль. Хайваннар турындагы әкиятләр, җырлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Уналтынчы шөгыль. Кошлар турындагы әкиятләр, җырлы уеннар. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Унҗиденче шөгыль. Татарлар. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Унсигезенче шөгыль. Руслар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Татар дөньясы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Унтугызынчы шөгыль. Сабантуй. . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Егерменче шөгыль. Милли ризыклар . . . . . . . . . . . . . . 47
Егерме беренче шөгыль. Милли киемнәр . . . . . . . . . . . 48
Егерме икенче шөгыль. Татар халык биюләре. . . . . . . . . 50
Егерме өченче шөгыль. Тукай геройлары . . . . . . . . . . . 53
Файдаланылган әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58

Учебное издание

**Шакурова Муслима Магесумовна**
**Гиниятуллина Лилия Миннулловна**

**ЯЗЫК КРАСЕН СЛОВАМИ**

Методическое пособие
для воспитателей образовательных организаций дошкольного образования
(для изучающих татарский язык как родной)

(на татарском языке)

Художник А. Б. Шляпкин

Верстка Н.Т. Абдуллиной

Подписано в печать 20.12.2021.
Формат 60×84$^1/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman
Печать офсетная. Усл. печ. л. 3,5. Уч.-изд. л. 2. Тираж 500 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20